**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 декабрь № 918

г. Казань

2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү стратегиясен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру буенча чаралар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 2 июнь, 6-1083 нче боерыгы белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү стратегиясен тормышка ашыруны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы икътисад министры А.А.Здуновны Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче;

2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү.».

3. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына:

2016 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләр турында тәкъдимнәр кертергә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлык буенча совет турында» 2015 ел, 30 декабрь, ПУ-1271 нче Указына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлык буенча советны Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча киңәшмә орган буларак билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү;

2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү стратегиясендә каралган максатчан күрсәткечләргә ирешкән өчен вазыйфаи затларга премияләр бирү системасын гамәлгә кертү;

2017 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү стратегиясенең төп нигезләмәләрен һәм максатчан юнәлешләрен исәпкә ала торган «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасын эшләүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» акционерлык җәмгыяте белән 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне даими нигездә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\918.docx